**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**муниципального образования**
**«поселок городского типа**
**Актюбинский» Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Губкина, д. 24, п.г.т. Актюбинский,
Азнакаевский муниципальный район,
423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**«Актүбә шәһәр тибындагы поселок»**
**муниципаль берәмлеге**
**БАШЛЫГЫ**

Губкин урамы, 24 йорт, Актүбә ш.т.п.,
Азнакай муниципаль районы, 423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» гыйнвар 2026 ел № 1

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 31.10.2025 №1, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында" 31.10.2025 №2, гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль Законның 45 статьясы, 69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставның 14.1 статьясы нигезендә, карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 31.10.2025 №1, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль

берәмлеге территориясендә 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында" 31.10.2025 №2, гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыенын билгеләү турында Актюбинская, Булатова, Нагорная, Пушкин, Садовая, Сайдашев, Строительная, Тукай, Х.Такташ урамнары буенча теркәлгән гражданнар өчен 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2026 елның 06 февралендә 17 сәгать 00 минутка гражданнар җыенын билгеләргә.

Үткәрү урыны: Актюбинская урамы, 41 адресы буенча урнашкан мәчет янында.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 31.10.2025 №1, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 31.10.2025 №2 карарына түбәндәге редакциядәге чара үзгәрешләр кертергә ризамы:

«- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең иске өлешендә урнашкан елга үзәнен чистарту):

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес: http://pravo.tatarstan.ru буенча һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес: http://aznakayevo.tatarstan.ru буенча, Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Актүбә ш.т.п., Губкин ур., 24 өй адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында 10 көн эчендә кабул ителгәннән соң урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык А.Л. Севостьянов